**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТОЙГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКАИ ТАТАРСТАН**
пер. Школьный, д.7,
д. Тойгузино, Менделеевский район,
Республика Татарстан, 423646

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТОЙГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Мәктәп тыкрыгы, 7 йорт,
Тойгуҗа авылы, Менделеевск районнары,
Татарстан Республикасы, 423646

Тел. (факс): (85549) 3-40-13
e-mail: Toyg.Men@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 елның 22 марты №5

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
"Тойгуҗа авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең
җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә
үзгәрешләр кертү проекты буенча
ачык тыңлаулар үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясы, Тойгуҗа авыл җирлеге Уставы, гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлеге башкарма комитетының административ бинасында 2024 елның 18 апрелендә 16 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: Менделеевск районы, Тойгуҗа авылы, Мәктәп тыкрыгы, 7 йорт, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Тойгуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар уздырырга.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча ачык тыңлауларны оештыру һәм уздыру өчен түбәндәге составта комиссия төзергә:

Сафин Р.А. - Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлеге башлыгы, комиссия рәисе;

Кудрина Г.Р. - Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлеге советы рәисе урынбасары»;

Хәбибрахимов Р. - Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлеге депутаты (килешү буенча).

3. 2024 елның 22 мартыннан 18 апреленә кадәрге чорда Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында

«Тойгуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проекты материаллары экспозициясен түбәндәге адрес буенча оештырырга: Менделеевск районы, Тойгуҗа авылы, Мәктәп тыкрыгы, 7 й.

4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә (җибәрелә): 423646, Татарстан Республикасы, Менделеевск районы, Тойгуҗа авылы, Мәктәп тыкрыгы, 7 йорт (Менделеевск муниципаль районының Тойгуҗа авыл җирлеге башлыгы исеменә).

5. Әлеге карарны, Тойгуҗа авылындагы махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштырып, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru "Тойгуҗа авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Глава Тойгузинского
сельского поселения

Р.А. Сафин